КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 июль г.Казань № 584

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 21 июль, 381 нче; 2009 ел, 23 ноябрь, 795 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 36 нчы; 2012 ел, 10 май, 364 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 5 пунктны тормышка ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктта «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктта «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнгә кадәр билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеге гамәлдә санала дип билгеләргә.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе карары нигезендә бетерелгән вазыйфалар яки элегрәк ябылган дәүләт органнары вазыйфалары буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең айлык акчалата керемнәре турында белешмә кәгазьләрен рәсмиләштерүне гамәлгә ашырырга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе составы»;

комиссия составыннан Ч.Н.Гайзатуллинаны, Р.Р.Дәүләтшинаны, Р.М.Ихсановаиы, Ю.Н.Олоноваиы, Е.М.Потаповаиы, Т.Х.Фәсхетдиноваиы, А.Р.Хәсәноваиы чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе Рөстәм Фәйзрахман улы Вәлиулловны;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының идарә аппаратын финанслау бүлеге башлыгы Альбина Әлфир кызы Вәлитованы;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының дәүләт хезмәтен үстерү бүлеге баш киңәшчесе Ләйсән Рамил кызы Низамованы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы Ирина Мирзаҗан кызы Сергееваны;

И.Г.Пенькова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге төп киңәшчесе, комиссия секретаре»;

әлеге карар белән расланган Дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе турында нигезләмә»;

1 нче пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәүне тәэмин итү максатларында төзелде» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 5 нче пунктын үтәүне тәэмин итү максатларында төзелде» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссиянең төп функциясе – дәүләт граждан хезмәтенең бетерелгән вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү хокукын бирүче вазыйфаларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә тиешле елларны эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына кертелгән вазыйфаларга тәңгәллеген билгеләү.»;

4 нче пунктта «Дәүләт хезмәтенең элегрәк бетерелгән вазыйфаларының» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең элегрәк бетерелгән вазыйфаларының» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктта «гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча дәүләт хезмәте вазыйфаларының элегрәк билгеләнгән тәңгәллеген» сүзләрен – «гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының элегрәк билгеләнгән тәңгәллеген» сүзләренә, «Дәүләт хезмәтенең бетерелгән вазыйфалары һәм дәүләт хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү хокукын бирә торган вазыйфаларның тәңгәллеген билгеләүгә йогынты ясый торган өстәмә материаллар тәкъдим ителгән очракта» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең бетерелгән вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү хокукын бирә торган вазыйфаларның тәңгәллеген билгеләүгә йогынты ясый торган өстәмә материаллар тәкъдим ителгән очракта» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның икенче абзацында «дәүләт хезмәтендә тиешле елларны эшләгән буенча пенсиягә» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин